Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кама-Исмәгыйль авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел № 97

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 70 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Кама-Исмәгыйль авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 70 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 105 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 125 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 81 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 4 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 86 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы, Кама-Исмәгыйль авылы,Ленин ур., 92а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кама-Исмәгыйль авыл
җирлеге башлыгы А.З.Шайдуллина